ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2016 елның 9 июне**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1560**

Зеленодольск шәһәре, Украина урамы, 23 йорт адресы буенча урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын һәм җир кишәрлеген тартып алу турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 26 сентябрендәге 2178 номерлы карары белән расланган 2013-2017 елларга Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча Зеленодольск муниципаль районы муниципаль адреслы программаны тормышка ашыру максатында, 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» Федераль законы, Россия Федерациясе Торак, Җир кодекслары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск шәһәре, Украина урамы, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле күпфатирлы Украина урамы, 23 нче номерлы торак йорттагы җир кишәрлеген, шулай ук әлеге йортта урнашкан исемлек буенча күчемсез мөлкәт объектларын (торак һәм торак булмаган биналарны) муниципаль ихтыяҗлар өчен тартып алырга (кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен:

- тартып алына торган күчемсез мөлкәтнең хокук ияләренә;
- күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәлүен башкаручы органга;

- "Торак сәясәте департаменты" МКУна җибәрергә.

4. «Зеленодольск муниципаль районы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль учреждениесенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслауны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2016 елның
9 июнендәге 1560 номерлы карарына
кушымта

Украина урамы, 23 нче күпфатирлы торак йортта урнашкан
авария дип танылган һәм сүтелергә тиешле тартып алына торган
күчемсез мөлкәт объектлары (торак, торак булмаган биналар)
исемлеге

| Фатир № | Объектның кадастр (яисә) шартлы номеры |
|---|---|
| 2 | 16:49:012101:4001 |
| 4 | 16:49:012101:4003 |
| 7 | 16:49:012101:4014 |
| 11 | 16:49:012101:4006 |
| 12 | 16:49:012101:4007 |